ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 437-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары А.К. Хамаев, Т.Г. Һадиев, И.Г. Ганиев тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» 437-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 13 июле
№ 2070-VI ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
А.К. Хамаев,
Т.Г. Һадиев,
И.Г. Ганиев
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» 2021 елның 5 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 4 пунктына (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2021, № 36 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4) органик продукция җитештерүчеләр – органик продукция җитештерүне, саклауны, маркировкалауны, транспортировкалауны һәм реализацияләүне гамәлгә ашыра торган һәм органик продукция җитештерүчеләрнең бердәм дәүләт реестрына кертелгән юридик һәм физик затлар, чит ил юридик затлары, чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты Татарстан Республикасы законнарын федераль законнарга туры китерү максатларында эшләнде.

2023 елның 1 сентябреннән үз көченә керә торган «Органик продукция турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законның 2 һәм 6 статьяларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 29 декабрендәге 630-ФЗ номерлы Федераль закон белән «Органик продукция турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 3 августындагы 280-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертелде, алар нигезендә органик продукция җитештерүчеләргә органик продукция җитештерүне, саклауны, маркировкалауны, транспортировкалауны һәм реализацияләүне гамәлгә ашыра торган һәм органик продукция җитештерүчеләрнең бердәм дәүләт реестрына кертелгән чит ил юридик затлары, чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар кертеләчәк.

Шуңа бәйле рәвештә закон проектында «Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» 2021 елның 5 маендагы 34-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында кулланыла торган «органик продукция җитештерүчеләр» төшенчәсе төгәлләштерелә.

**«Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы башка законнарының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.